**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАР

**14 ноябрь 2022 ел.** **№13**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегендә халык җыены үткәрү турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2022 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә, үткәрү урыны: Каенсар авылы, Һ. Такташ урамы., 23 адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасы.

2.Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2022 елның 25 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә, үткәрү урыны: Каенсар авылы, Һ. Такташ урамы., 23 адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасы.

3. Кукмара муниципаль районы Каенсар авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2022 елның 26 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә, үткәрү урыны: Каенсар авылы, Һ. Такташ урамы., 23 адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасы.

4.. Кукмара муниципаль районының Каенсар авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучылар һәм студентларлан(курсантлардан), 1 төркем инвалидлардан, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләрдән,18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә һәм аннан да өлкәнрәк затлардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлардан тыш , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча, җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2023 елда үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- Каенсар авылының 1Май урамына вак таш җәелгән юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү һәм техник күзәтчелек);

- Каенсар авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Каенсар авылы урамнарын яктырту өчен лампалар сатып алу.

- Каенсар авылының артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу.

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә кирәк.

6. Җыенны Каенсар авыл җирлеге башкарма комитеты оештыра..

7. Әлеге карарны, мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән, кабул ителгән көннән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә кирәк.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Каенсар авыл жирлеге башлыгы И.Х.Исхаков